**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ МУРТЫШ-ТАМАК**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ**
**01.11.2024**

**КАРАР**
**№ 11**

Сарман муниципаль районының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 22 маендагы 6 номерлы Мортыштамак авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мортыштамак авыл җирлеге советы карар итте:

1.Сарман муниципаль районының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау турында» Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл җирлеге Советы 6 номерлы 22 май 2020 елгы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 9.2 пунктының 6 абзацында «түләнергә тиешле сумманы исәпләгән көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 7 абзац өстәргә:

«бюджетка түләүләр буенча дебитор бурычларын, пенялар һәм штрафлар буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру регламентын билгеләү;»;

2) 9 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«туристлык салымы - 100 процент норматив буенча.»;

2. Әлеге карарның 1 пунктның 2 пунктчасы 01.01.2025 елдан үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда әлеге карарны игълан итәргә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге
Совет рәисе

Һадиуллин И.Н.